СОВЕТ БУРНАШЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
БУРНАШ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

17.10.2022 с. Татарское Бурнашево 23-125

Гражданнарның үзара салымын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Югары Ослан муниципаль районының Борнаш авыл җирлеге Татар Борнашы авылы торак пункты территориясендә гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 ст. нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Борнаш авыл җирлеге Уставының 24 ст. нигезендә

Югары Ослан муниципаль районының
Борнаш авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. 2022 елның 29 октябренә Югары Ослан муниципаль районының Борнаш авыл җирлеге Татар Борнашы авылы территориясендә гражданнарның үзара салым акчасын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.
2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2023 елда Югары Ослан муниципаль районының Борнаш авыл җирлегенең Татар Борнашы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 3500 сум күләмендә үзара салым җыюга һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрүгә сез ризамы:

- Татар Борнашы авылы Яңа урамында юл салу өчен вак таш сатып алу

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Татар Борнашы авылы, Яшьләр урамы, 1А йорты каршында 15.00 сәгатьтә гражданнар җыенын үткәрергә.
4. Җыенны оештыручы итеп Борнаш авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.
5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, шулай ук җирлекнең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.
6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Совет рәисе,
Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районының
Борнаш авыл җирлеге башлыгы С. В. Бурукин